Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге Советының егерме тугызынчы утырышы

Пановка авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

15 декабрь, 2023 ел № 81

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында» 2016 елның 21 апрелендәге 21/4 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын тану турында, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында»

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Пановка авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында» 2016 елның 21 апрелендәге 24/4 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары (2022 елның 3 июнендәге 39 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үз көчләрен югалткан дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Пановка авыл җирлеге башлыгы О.И. Козырев